## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Түбән Ләшәү авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2020 ел, 13 ноябрь** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә 11.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 250 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Түбән Ләшәү авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; ялгыз,өлкән булган затлардан; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) Түбән Ләшәү авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампочкалар һәм яктырткычлар сатып алу);

2) Түбән Ләшәү авылында "МТЗ-82" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү) ;
3) Түбән Ләшәү авылы урамнарын кардан чистарту, карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү) ;
4) Түбән Ләшәү авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилейлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Яңа ел) үткәрү өчен бүләкләр алу;

5) “Сарман” район газетасында некролог бастыру;
6) Җәйге чорда авыл территориясен чабу өчен бензокосилкага ГСМ алу;

7) Түбән Ләшәү авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырлар ремонтлау, вак таш ташу);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 69 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 41 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 41 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл жирлегенең Түбән Ләшәү авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2021 елда 250 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Түбән Ләшәү авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, ялгыз өлкән булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге

эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1)Түбән Ләшәү авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампочкалар һәм яктырткычлар сатып алу);

2)Түбән Ләшәү авылында "МТЗ-82" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү) ;

3)Түбән Ләшәү авылы урамнарын кардан чистарту, карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү) ;

4)Түбән Ләшәү авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилейлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Яңа ел) үткәрү өчен бүләкләр алу;

5)“Сарман” район газетасында некролог бастыру;

6)Җәйге чорда авыл территориясен чабу өчен бензокосилкага ГСМ алу;

7)Түбән Ләшәү авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырлар ремонтлау, вак таш ташу) һәм аларны түләү кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Түбән Ләшәү мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче И.З.Хабибуллин